Большие Ключи авыл җирлеге чиге Бишнә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Большие Ключи, Бишнә һәм Осиново авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановский авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 38 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 300 м 38 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньякка таба 2,2 км 38, 29, 16 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, канауны кисеп үтеп, 100 м 159 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап, Сумка елгасын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 350 м 138 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 200 м көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 138 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 137 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 137 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Большие Ключи авыл җирлеге чиге Осиново авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Большие Ключи, Осиново һәм Раифа авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановский авылыннан 850 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км, «Мәскәү — Уфа» — Ивановский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 50 нче, 51 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м 52 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Большие Ключи авыл җирлеге чиге Раифа авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 3,4 км, ике мәртәбә канауны кисеп үтеп, «Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы» ФДБУ төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м урман массивы буйлап Сумка елгасын һәм инешне кисеп

үтеп уза, аннары көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 900 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әйшә участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 300 м урман полосасы буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 250 м 50 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 300 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көнбатышка таба 100 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 450 м урман полосасы буйлап, 200 м урман массивының көньяк чиге буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, «Казан – Йошкар-Ола» – Олы Күлбаш – Дөбъяз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 1,2 км 50 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивы буйлап уза, аннары көнбатышка таба 450 м «Казан – Йошкар-Ола» – Олы Күлбаш» – Маевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап, 50 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, 250 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап, 300 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Казан – Йошкар-Ола» – Олы Күлбаш» – Маевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман массивы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 150 м, урман массивын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 200 м, көньяк-көнбатышка таба 400 м бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м 52 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м һәм көнбатышка таба 1,0 км «Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы» ФДБУ төньяк чиге буйлап Большие Ключи, Раифа һәм Әйшә авыл җирлекләре

чикләре тоташкан урында Маевка авылыннан 850 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Большие Ключи авыл җирлеге чиге Әйшә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 56 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 2,7 км «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әйшә участок урманчылыгындагы 10, 9, 8 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 55 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

## Зеленодольск муниципаль районының «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олы Карагуҗа авыл җирлеге Бишнә, Большие Ключи, Олы Җәке авыл җирлекләре, Биектау муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы белән чиктәш.

Олы Карагуҗа авыл җирлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә Олы Карагуҗа, Олы Җәке авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Олы Җәке авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Олы Карагуҗа авыл җирлеге, Биектау муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Чирүчи авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 4 нче (10 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Карагуҗа авыл җирлеге чиге Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә 4 нче (10 нчы) тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап Олы Карагуҗа, Бишнә авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль рай-

оны чикләре тоташкан урында Синтәк авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Карагуҗа авыл җирлеге чиге Бишнә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 350 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 300 м көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 156 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Олы Күлбаш – Бишнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м 154 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 250 м урман массивы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 950 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 350 м 136 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 30 м 136 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 650 м 137 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Олы Карагуҗа, Бишнә һәм Большие Ключи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Кармыш авылыннан 1,2 км көнбатышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Карагуҗа авыл җирлеге чиге Большие Ключи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м

урман полосасының көньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 200 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 136 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, 250 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м урман массивы буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 900 м 156 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, төньякка таба 150 м, агач-куак үсемлекләре массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап буага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м буа буйлап бара, аны кисеп үтеп, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,2 км буаның уң яры буйлап уза, 250 м инеш агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, 400 м шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, «Казан – Йошкар-Ола» – Олы Күлбаш – Дөбъяз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап 30 м уза, шуннан соң көньякка таба, Большие Ключи – Уразлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 550 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 800 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әйшә участок урманчылыгындагы 49 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Олы Карагуҗа, Большие Ключи һәм Олы Җәке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Большие Ключи авылыннан 750 м төньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Карагуҗа авыл җирлеге чиге Олы Җәке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 800 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара,

шуннан соң көньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Петьялка елгасын һәм агач-куак үсемлекләренең яр буе полосасын кисеп үтеп, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Олы Җәке һәм Олы Карагуҗа авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 550 м урман полосасы буйлап, 500 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м урман массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Большие Ключи – Уразлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 40 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әйшә участок урманчылыгындагы 48 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

1) 13 – 17 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картасхемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олы Шырдан авыл җирлеге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр авыл җирлеге һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Олы Шырдан авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә Олы Шырдан, Олы Ачасыр авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Кече Шырдан авылыннан 3,0 км төньяк-көнбатышта «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 10 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 51 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Олы Шырдан авыл җирлеге, «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Рус Шырданы авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 52 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шырдан авыл җирлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр һәм Олы Шырдан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Шырдан авылыннан 1,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 30 м агач-куак үсемлекләре массивының төньяк чиге буйлап, 50 м урман массивы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 400 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 21 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 40 м чокыр буйлап һәм көньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 350 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 900 м урман полосасына кадәр бара, чокырны кисеп үтеп, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 100 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 250 м бара, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км көньяк-көнчыгыш чиге буй-

лап уза, «Карамалы Тау – Албаба тимер юл разъезды поселогы» – Олы Шырдан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 30 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 850 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,6 км күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр бара, 950 м аның агымы буенча аска таба уза, аннары, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, Секерка елгасын, ике мәртәбә инешне һәм аның текә ярын, күлне һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км уза, шуннан соң көнбатышка таба 350 м профильле автомобиль юлы буйлап, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап күмәк бакчаларга кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр, 4,3 км шушы инеш агымы буенча өскә таба, дамбаны һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 52 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шырдан авыл җирлеге чиге Олы Ачасыр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 750 м башка кибеп баручы инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, 2,6 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 40 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м 18 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, 800 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 350 м 17 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м 17 нче урман кварталы буйлап уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км 17 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м 17 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 200 м ур-

ман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Секерка елгасына кадәр уза, 1,8 км әлеге елга агымы буенча аска таба аңа инеш койган җиргә кадәр бара, 500 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буа плотинасына кадәр уза, сынык сызык ясап, 50 м плотинаның төньяк чиге буйлап бара, 150 м буаның сул яры буйлап һәм яңадан шушы инеш агымы буенча өскә таба 450 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,9 км 10 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 600 м төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 51 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

## Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олы Җәке авыл җирлеге Большие Ключи, Олы Карагуҗа авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы белән чиктәш.

Олы Җәке авыл җирлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә Олы Җәке, Большие Ключи авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Малые Ключи авылыннан 950 м төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Олы Җәке, Олы Карагуҗа авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташ-

кан урында Олы Җәке авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Җәке авыл җирлеге чиге Олы Карагуҗа авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 150 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 800 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Петьялка елгасын һәм агач-куак үсемлекләренең яр буе полосасын кисеп үтеп, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Олы Җәке һәм Олы Карагуҗа авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 550 м урман полосасы буйлап, 500 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м урман массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Большие Ключи – Уразлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 40 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әйшә участок урманчылыгындагы 48 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Олы Җәке, Олы Карагуҗа һәм Большие Ключи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Большие Ключи авылыннан 750 м төньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Җәке авыл җирлеге чиге Большие Ключи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 50 м «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әйшә участок урманчылыгындагы 48 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 48 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м 48 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 700 м урман массивының көньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 850 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 5,0 км 1, 2, 3 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш

чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

## Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Күгәй авыл җирлеге Акъегет, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Түбән Урысбага, Норлат, Рус Әҗиле, Өтәшкә авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Күгәй авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә Күгәй, Мамадыш-Әкил авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Мамадыш-Әкил авылыннан 2,8 км төньякта «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Күгәй, Акъегет авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Бакырчы авылыннан 4,6 км көньякта 70 нче урман кварталының төньяк почмагында урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгәй авыл җирлеге чиге Акъегет авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күгәй, Акъегет һәм Күгеш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урман поселогыннан 2,5 км көнбатышта «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталының төньяк почмагында урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 3,2 км 57, 56, 71, 70 нче урман квартalla-

рының төньяк-көнбатыш, төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгәй авыл җирлеге чиге Күгеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күгәй, Күгеш һәм Түбән Урысбага авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Исламы авылыннан 2,6 км төньякта урнашкан 47 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 200 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешнең текә ярын кисеп үтеп, 100 м чокыр буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярларны кисеп үтеп, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, буаны кисеп үтеп, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әрә елгасына кадәр бара, 100 м әлеге елга агымы буенча өскә таба аңа Ухта елгасы койган җиргә кадәр уза, 950 м әлеге елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, Норлат – Акъегет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, чокырны һәм шушы инешнең текә ярын кисеп үтеп, 800 м аның агымы буенча өскә таба бара, аннары көньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 600 м 31 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,9 км 36, 35, 44 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 44 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м 44 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң көнбатышка таба 750 м 57 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 48 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгәй авыл җирлеге чиге Түбән Урысбага авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күгәй, Түбән Урысбага һәм Норлат авыл

җирлекләре чикләре тоташкан урында Косякау авылыннан 1,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, Төрләмә – Норлат – Борындык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 900 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 26 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, текә ярларны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 450 м чокыр төбеннән бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын һәм текә ярны кисеп үтеп, 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгәй авыл җирлеге чиге Норлат авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күгәй, Норлат һәм Өтәшкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карашәм авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының көнчыгыш чигендә урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 350 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 400 м һәм көньяк-көнбатышка таба 600 м төньяк чиге буйлап уза, аннары көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 55 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 250 м уза, аннары көнбатышка таба 600 м һәм төньяк-көнбатышка таба 200 м 54 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 650 м 54 нче, 43 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 300 м 43 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап һәм 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м 43 нче урман кварталының төнь-

як-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр уза, 350 м аның агымы буенча аска таба буага кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба 250 м буаның сул яры буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 250 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырга кадәр уза, 1,1 км чокыр төбеннән Малая елгасына кадәр бара, 200 м әлеге елга агымы буенча өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 350 м чокыр төбеннән бара, 200 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Норлат – Акъегет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 400 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 800 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 100 м 106 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап зиратка кадәр бара, 50 м зиратның көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әрә елгасына кадәр уза, чокырны кисеп үтеп, 1,1 км әлеге елга агымы буенча аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 500 м әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 700 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, Әрә елгасына кадәр бара, 1,3 км әлеге елга агымы буенча, Төрләмә – Норлат – Борындык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аска таба уза, шуннан соң төньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 250 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 1,4 км шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Төрләмә – Норлат – Борындык» – Рязаново автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м урман полосасы буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгәй авыл җирлеге чиге Өтәшкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күгәй, Өтәшкә һәм Рус Әҗиле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карашәм авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 69 нчы урман кварталының көнчыгыш чигендә урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 55 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм көнбатышка таба 250 м көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 500 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгәй авыл җирлеге чиге Рус Әҗиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күгәй, Рус Әҗиле һәм Мамадыш-Әкил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Панау авылыннан 3,2 км төньякта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м 65 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм төньякка таба 750 м көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 600 м 50 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 950 м 51 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 3,0 км 66, 53, 67, 68, 69 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 600 м 69 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгәй авыл җирлеге чиге Мамадыш-Әкил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 80 нче, 81 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Татар Әҗиле – Күгәй автомобиль юлына кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба шушы автомобиль юлы буйлап 500 м уза, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 450 м 82 нче, 83 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км 83 нче, 84 нче

урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 450 м 84 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 950 м 78 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм төньякка таба 150 м көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км 64 нче, 65 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
16 нчы кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Күгеш авыл җирлеге Акъегет, Күгәй, Түбән Урысбага авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Күгеш авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә Күгеш, Акъегет авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Тугай авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Күгеш, Түбән Урысбага авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Бәчек авылыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгеш авыл җирлеге чиге Түбән Урысбага авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күгеш, Түбән Урысбага һәм Күгәй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Исламы авылыннан 2,6 км төньякта урнашкан 47 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 2,0 км бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап урман полосасына кадәр бара, текә ярны кисеп үтеп, 1,6 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгеш авыл җирлеге чиге Күгәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 200 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешнең текә ярын кисеп үтеп, 100 м чокыр буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярларны кисеп үтеп, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, буаны кисеп үтеп, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әрә елгасына кадәр бара, 100 м әлеге елга агымы буенча өскә таба аңа Ухта елгасы койган җиргә кадәр уза, 950 м әлеге елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, Норлат — Акъегет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, чокырны һәм шушы инешнең текә ярын кисеп үтеп, 800 м аның агымы буенча өскә таба бара, аннары көньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 600 м 31 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,9 км 36, 35, 44 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 44 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м 44 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 750 м 57 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап Күгеш, Күгәй һәм Акъегет авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урман поселогыннан 2,5 км көнбатышта 57 нче урман кварталының төньяк почмагында урнашкан 48 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күгеш авыл җирлеге чиге Акъегет авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 48 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 600 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м чокыр төбе буйлап Ухта елгасына кадәр уза, 1,5 км әлеге елга агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 250 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м бара, 650 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешне кисеп үтеп, 800 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, Укша инешен һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 350 м урман полосасы буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м үләт базының төньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Норлат — Акъегет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Әрә елгасының текә ярын кисеп үтеп, 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Күгәй, Рус Әҗиле авыл җирлекләре, Кайбыч муниципаль районы һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Мамадыш-Әкил авыл җирлеге чиге Кайбыч муниципаль районы белән чиктәш җирдә Мамадыш-Әкил, Рус Әҗиле авыл җирлекләре һәм Кайбыч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Рус Әҗиле авылыннан 1,7 км төньяк-көнбатышта Гөбенә елгасы акваториясендә урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап Мамадыш-Әкил авыл җирлеге, Кайбыч муниципаль районы һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Мамадыш-Әкил авылыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче (9 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Мамадыш-Әкил авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә 41 нче (9 нчы) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Мамадыш-Әкил, Күгәй авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Мамадыш-Әкил авылыннан 2,8 км төньякта «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мамадыш-Әкил авыл җирлеге чиге Күгәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 80 нче, 81 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Татар Әҗиле – Күгәй автомобиль юлына кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба шушы автомобиль юлы буйлап 500 м уза, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 450 м 82 нче, 83 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км 83 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 450 м 84 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 950 м 78 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм төньякка таба 150 м көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км 64 нче, 65 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Мамадыш-Әкил, Күгәй һәм Рус Әҗиле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Панау авылыннан 3,2 км төньякта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мамадыш-Әкил авыл җирлеге чиге Рус Әҗиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып, Татар

Әҗиле – Күгәй автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньякка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 750 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 150 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак үсемлекләре массивын кисеп үтеп, 100 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньякка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

2) 19 – 28 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>19 нчы кушымта

## Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Мулла Иле авыл җирлеге Олы Ачасыр, Норлат, Өтәшкә авыл җирлекләре һәм Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш.

Мулла Иле авыл җирлеге чиге Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш җирдә Мулла Иле, Олы Ачасыр авыл җирлекләре һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бритвино авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап Мулла Иле, Өтәшкә авыл җирлекләре һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Городище авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта Зөя елгасы акваториясендә урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мулла Иле авыл җирлеге чиге Өтәшкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 70 м Зөя елгасы буйлап аның сул ярына кадәр бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 450 м, сазлыкны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 150 м Таганлык күленә кадәр уза, аннары көнбатышка таба 100 м шушы күл буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Киндер күлен кисеп үтеп, 700 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка

үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 3,0 км 66, 53, 67, 68, 69 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 600 м 69 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап Рус Әҗиле, Күгәй һәм Өтәшкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карашәм авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта 69 нчы урман кварталының көнчыгыш чигендә урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Рус Әҗиле авыл җирлеге чиге Өтәшкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м, Гөбенә елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 150 м бара, сынык сызык ясап, 150 м күл буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 100 м, көнбатышка таба 150 м бара, күл буйлап көнбатышка таба 150 м, төньякка таба 350 м уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 950 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 108 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, 600 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 950 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 900 м 91 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм төньякка таба 800 м көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 100 м 90 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап һәм көнбатышка таба 550 м төньяк чиге буйлап бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 500 м 89 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, көнбатышка таба 150 м төньяк чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 300 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 150 м урман полосасы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Төрләмә —

Норлат – Борындык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәруза.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
27 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Свияжск (Зөя) авыл җирлеге «Васильево шәһәр тибындагы поселогы», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре, Әйшә авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш.

Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш җирдә Свияжск (Зөя) авыл җирлеге, «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Васильево шәһәр тибындагы поселогыннан 2,6 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы», Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Свияжск (Зөя) авылыннан 1,1 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=472689,99, Y=1277303,41 координаталы 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 7,3 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, утрауны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 5,6 км Куйбы-

шев сусаклагычының уң яры буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 3,2 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, утрауны кисеп үтеп, «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре, Әйшә һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 479365,96, Y = 1271527, 30 координаталы 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге Әйшә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 3,3 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Свияжск (Зөя) һәм Әйшә авыл җирлекләре, «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Васильево шәһәр тибындагы поселогыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=478416,66, Y=1274733,55 координаталы 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 2,8 км төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
28 нче кушымта

## Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Өтәшкә авыл җирлеге Күгәй, Мулла Иле, Норлат, Рус Әҗиле авыл җирлекләре, Югары Ослан һәм Кайбыч муниципаль районнары белән чиктәш.

Өтәшкә авыл җирлеге чиге Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш җирдә Өтәшкә, Мулла Иле авыл җирлекләре һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Городище авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта Зөя елгасы акваториясендә урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап Өтәшкә авыл җирлеге, Югары Ослан һәм Кайбыч муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Утяково авылыннан 2,6 км көньякта Зөя елгасы акваториясендә урнашкан X=447530,00, Y=1262892,76 координаталы 34 нче (39 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Өтәшкә авыл җирлеге чиге Кайбыч муниципаль районы белән чиктәш җирдә 34 нче (39 нчы) тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап Өтәшкә, Рус Әҗиле авыл җирлекләре һәм Кайбыч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Салатчы авылыннан 200 м көньяк-көнбатышта Гөбенә елгасы акваториясендә урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Өтәшкә авыл җирлеге чиге Рус Әҗиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м, Гөбенә елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 150 м бара, сынык сызык ясап, 150 м күл буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 100 м, көнбатышка таба 150 м бара, күл буйлап көнбатышка таба 150 м, төньякка таба 350 м уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 950 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 108 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, 600 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 950 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 900 м 91 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм төньякка таба 800 м көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

уза, аннары төньякка таба 100 м 90 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап һәм көнбатышка таба 550 м төньяк чиге буйлап бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 500 м 89 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, көнбатышка таба 150 м төньяк чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 300 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 150 м урман полосасы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Төрләмә – Норлат – Борындык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Өтәшкә, Рус Әҗиле һәм Күгәй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карашәм авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта 69 нчы урман кварталының көнчыгыш чигендә урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Өтәшкә авыл җирлеге чиге Күгәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм көнбатышка таба 250 м көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 500 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Өтәшкә, Күгәй һәм Норлат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карашәм авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта 55 нче урман кварталының көнчыгыш чигендә урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Өтәшкә авыл җирлеге чиге Норлат авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 750 м, Төрләмә – Норлат – Борындык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 300 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 850 м, чокырны кисеп үтеп, Өтәшкә, Норлат һәм Мулла Иле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Норлат авылыннан 2,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Өтәшкә авыл җирлеге чиге Мулла Иле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 70 м Зөя елгасы буйлап аның сул ярына кадәр бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 450 м, сазлыкны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка

таба 150 м Таганлык күленә кадәр уза, аннары көнбатышка таба 100 м шушы күл буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Киндер күлен кисеп үтеп, 700 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 600 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 3,4 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, Албаба станциясе – Бузаево автомобиль юлына һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 2,2 км шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 20 м һәм төньяк-көнбатышка таба 500 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м чокыр буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1379. Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Балтач муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртергә:

1) әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә «Борнак авыл җирлеге»нең һәм «Яңгул авыл җирлеге»нең;

2) әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә «Чепья авыл җирлеге»нең һәм «Нөнәгәр авыл җирлеге»нең.

**2 статья**

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 8 (III өлеш); 2012, № 9) әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 декабре
№ 144-ТРЗ

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Балтач муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

Муниципаль берәмлекләр чикләренең тәкъдим ителгән үзгәрешләр исәпкә алынган

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б – Борнак авыл җирлегенең һәм Яңгул авыл җирлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге территориясе

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Балтач муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

Муниципаль берәмлекләр чикләренең тәкъдим ителгән үзгәрешләр исәпкә алынган

<u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- Балтач муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б – Чепья авыл җирлегенең һәм Нөнәгәр авыл җирлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен үзгәртү һәм
«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелә торган үзгәрешләр**

1 – 20 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2

# «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 17 (13) – 1 (Б) | - Марий Эл Республикасы |
| 1 (Б) – 25 (14) | - Киров өлкәсе |
| 25 (14) – 38 (51) | - Кукмара муниципаль районы |
| 38 (51) – 37 (50) | - Саба муниципаль районы |
| 37 (50) – 17 (13) | - Арча муниципаль районы |

## «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Балтач шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Борбаш авыл җирлеге |
| 3 | Борнак авыл җирлеге |
| 4 | Югары Субаш авыл җирлеге |
| 5 | Карадуган авыл җирлеге |
| 6 | Куныр авыл җирлеге |
| 7 | Кече Лызи авыл җирлеге |
| 8 | Норма авыл җирлеге |
| 9 | Нөнәгәр авыл җирлеге |
| 10 | Пыжмара авыл җирлеге |
| 11 | Салавыч авыл җирлеге |
| 12 | Смәил авыл җирлеге |
| 13 | Сасна авыл җирлеге |
| 14 | Урта Көшкәт авыл җирлеге |
| 15 | Чепья авыл җирлеге |
| 16 | Шеңшеңәр авыл җирлеге |
| 17 | Шубан авыл җирлеге |
| 18 | Яңгул авыл җирлеге |

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

## «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең

һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Балтач муниципаль районы Марий Эл Республикасы, Киров өлкәсе, Арча, Саба һәм Кукмара муниципаль районнары белән чиктәш.

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Марий Эл Республикасы һәм Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Балтач, Арча муниципаль районнары һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Сасна Пүчинкәсе авылыннан 5,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 17 нче (13 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Балтач, Кукмара муниципаль районнары һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Алан авылыннан 8,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (14 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 25 нче (14 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнбатышка таба, Зур Китячка елгасын кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнчыгышка таба 1 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, аннары «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 250 м көньякка таба, 600 м көньяк-көнбатышка таба «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 19-К урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 21-К урман кварталының көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр уза, аннары 1,0 км көнбатышка таба әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап, 250 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 450 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 200 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 9 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр, 500 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кукмара участок урманчылыгындагы 9 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,2 км урман полосасының төньяк-

көнбатыш чиге буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 18 нче урман кварталының көнчыгыш чигенә кадәр бара, алга таба, сынык сызык ясап, 1,9 км көньякка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 18 нче, 22 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 650 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м чокыр буйлап, Бүре елгасын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары урман утыртмаларының төньяк чиге буенча 250 м көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,6 км һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 650 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 600 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә, сынык сызык ясап, 23 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 1,6 км көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 950 м көньяк-көнбатышка таба уза, инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,1 км төньяк-көнбатышка таба 26 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 3,4 км көньяк-көнбатышка таба 25 нче, 24 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 900 м көньякка таба 24 нче, 28 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 950 м көнбатышка таба 28 нче, 34 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,1 км көньяк-көнбатышка таба 34 нче, 33 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Балтач, Кукмара һәм Саба муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Нормабаш авылыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта 33 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 38 нче (51 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 38 нче (51 нче) тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 4,0 км «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 40, 49, 48 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Балтач, Саба һәм Арча муници-

паль районнары чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 6,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче (50 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 17 нче (13 нче) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасының төньяк почмагына кадәр уза, алга таба 300 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чигенә кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба 750 м шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, инешләрне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 3,9 км 53, 54, 55 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасының төньяк почмагына кадәр, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасы буенча бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 800 м урман полосасы буенча, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 109 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, Шубан елгасын кисеп үтеп, урман кварталының шушы аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, сынык сызык ясап, яңадан көньяк-көнбатышка таба 1,8 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 250 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 950 м, аннары көньякка таба 750 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, чокырны кисеп үтеп, 100 м ишелмә буйлап, 150 м урман массивы буенча, чокырны, яр буе агач-куак полосаларын һәм Шушма елгасын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м агач-куак массивы буйлап, Ашытбаш – Шушмабаш – Карадуган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Арча урманчылыгы»

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, урман кварталының шушы аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 400 м, чокырларны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, шушы урманчылыктагы 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 100 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м бара, аннары 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м һәм төньяк-көнбатышка таба көньяк-көнбатыш чиге буенча 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м һәм 68 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,5 км уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 68 нче, 70 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 1,2 км, 70 нче һәм 69 нчы урман кварталларының көньяк чиге буенча көнбатышка таба 2,5 км кибеп баручы инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буенча аска таба 1,4 км аның Хәтнә елгасына койган җиренә кадәр уза, шушы елга агымы буенча аска таба 150 м бара, 50 м көньякка таба агач-куак массивы буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, аннары 1,6 км шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 76 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба 76 нчы, 77 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, инешләрне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,8 км 73 нче, 71 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап Хәтнә елгасына кадәр уза, алга таба 2,4 км шушы елга агымы буенча аска таба бара, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 5,3 км шушы урманчылыкның 72, 75, 80, 87 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буенча, төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км 87 нче, 88 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, агач-куак массивын, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм канауны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,9 км уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 2,7 км «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Сурнар

участок урманчылыгындагы 1 нче, 2 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буенча, «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 110 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 200 м бара, аннары урман полосасының көньяк чиге буйлап 300 м, көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 1,5 км, урман полосасы буенча төньякка таба 200 м, урман полосасы буйлап көнчыгышка таба 1,8 км, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м 78 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 6,4 км 78, 77, 84, 89 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буенча уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 350 м шушы урманчылыкның 89 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Сурнар участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 750 м шушы урманчылыкның 67 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шушы урман кварталы буйлап көнчыгышка таба 500 м, сынык сызык ясап, 68 нче урман кварталының һәм шушы урманчылыкның 127 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 4,3 км, инешне кисеп үтеп, «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 69-К урман кварталы буйлап 1,1 км һәм 70-К урман кварталы буйлап 450 м 37 нче (50 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>3 нче кушымта

## Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге-

нең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Кече Лызи, Норма, Сасна һәм Шубан авыл җирлекләре белән чиктәш.

«Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Шубан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Шубан һәм Кече Лызи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Лызи-2 авылыннан 750 м көнчыгышта Шушма елгасында урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып 1,2 км Шушма елгасы агымы буенча аска таба «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Шубан һәм Сасна авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Лызи-2 авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта шушы елгада урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Сасна авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып, Балтач — Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 5,1 км Шушма елгасы агымы буенча аска таба «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Сасна һәм Норма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Сасна авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта Шушма елгасында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Норма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк-көнбатышка таба, Балтач — Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м көньякка таба, аннары көнчыгышка таба 500 м автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырга кадәр уза, 550 м чокырның төньяк-көнбатыш чиге буйлап Казан — Малмыж автомобиль юлына кадәр бара, 150 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, Казан — Малмыж, «Казан — Малмыж» — Нормабаш автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Норма елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 900 м уза, шуннан соң, «Казан — Малмыж» — Нормабаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,3 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км,

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Норма һәм Кече Лызи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Кече Лызи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, 81 нче, 80 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км, аннары, сынык сызык ясап, 76, 74, 72 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,4 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,0 км, шуннан соң, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 1,6 км, 350 м көньяк-көнбатышка таба, 750 м төньяк-көнбатышка таба уза, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, аннары урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 1,0 км, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 500 м уза, шуннан соң 60 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 450 м, Балтач – Кенәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м бара, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м төньяк-көнбатышка таба, 850 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнчыгышка таба «Балтач – Кенәбаш» – Зур Лызи автомобиль юлына кадәр бара, шушы автомобиль юлы буйлап төньякка таба 250 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньякка таба, 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньякка таба, 300 м көнчыгышка таба, Шушма елгасының текә ярын кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба Шушма елгасына кадәр, 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының «Борбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Борбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Борбаш авыл җирлеге Норма, Салавыч, Шеңшеңәр, Яңгул авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы белән чиктәш.

Борбаш авыл җирлеге чиге Яңгул авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Борбаш, Яңгул һәм Салавыч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Салавыч Сәрдегәне авылыннан 1,5 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, төньяк-көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 300 м бара, аннары урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасы буйлап 250 м, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км, төньяк-көнбатышка таба 200 м, төньяк-көнчыгышка таба 2,0 км, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 550 м, төньяк-көнчыгышка таба 350 м уза, урман полосасы буйлап 300 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м Борбаш, Яңгул һәм Шеңшеңәр авыл җирлекләре

чикләре тоташкан урында Яңгул авылыннан 4,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Борбаш авыл җирлеге чиге Шеңшеңәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 2,1 км көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 20-К урман кварталына кадәр уза, аннары 20-К, 21-К урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,2 км Борбаш, Шеңшеңәр авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Алан авылыннан 4,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Борбаш авыл җирлеге чиге Кукмара муниципаль районы белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып Балтач муниципаль районы чиге буйлап Борбаш, Норма авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Нормабаш авылыннан 500 м көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Борбаш авыл җирлеге чиге Норма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 80-К, 77-К, 74-К урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 4,1 км уза, аннары 74-К, 75-К, 76-К урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 2,5 км бара, шуннан соң 950 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап Борбаш, Норма һәм Салавыч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Борбаш авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Борбаш авыл җирлеге чиге Салавыч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып, Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,6 км «Балтач – Әтнә» – Борбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км, 250 м яңадан шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, «Балтач – Әтнә» – Борбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны

һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының «Борнак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Борнак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Борнак авыл җирлеге Смәил, Урта Көшкәт, Чепья, Шеңшеңәр һәм Яңгул авыл җирлекләре белән чиктәш.

Борнак авыл җирлеге чиге Чепья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Борнак, Чепья һәм Урта Көшкәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мельничная авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып 700 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Борнак, Чепья һәм Смәил авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карык-Серма авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Борнак авыл җирлеге чиге Смәил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып 850 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасың көньяк-көнбатыш чиге буйлап, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 300 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң көньякка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 750 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

350 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км кибеп баручы инешкә кадәр бара, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба 2,0 км бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шушма елгасына кадәр уза, Шушма елгасы буенча 10 м Борнак, Смәил һәм Шеңшеңәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Смәил авылыннан 900 м көньяк-көнбатышта шушы елгада урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Борнак авыл җирлеге чиге Шеңшеңәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып Шушма елгасы агымы буенча өскә таба 3,0 км Борнак, Шеңшеңәр һәм Яңгул авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Борнак авылыннан 1,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Борнак авыл җирлеге чиге Яңгул авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып, «Балтач – Әтнә» – Борбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Шушма елгасы агымы буенча өскә таба 4,5 км уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 10 м шушы елга буйлап аның уңъяк ярына кадәр, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Көшкәт елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 2,3 км бара, шуннан соң, Көшкәт елгасының текә сулъяк ярын кисеп үтеп, төньякка таба 250 м «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 100 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 43 нче урман кварталына кадәр уза, аннары, сынык сызык ясап, 43 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 950 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 43 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 950 м 42 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м Көшкәт елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 1,7 км Борнак, Яңгул һәм Урта Көшкәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Тау авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта Көшкәт елгасында урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Борнак авыл җирлеге чиге Урта Көшкәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Арча урманчы-

лыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, чокырны һәм аның төбеннән ага торган кибеп баручы инешне кисеп үтеп, шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 450 м һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, шуннан соң 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, урман массивы буйлап 250 м, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырга кадәр бара, шуннан соң чокыр буйлап төньяк-көнчыгышка таба 300 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньякка таба урман полосасына кадәр уза, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км һәм көнчыгышка таба 350 м «Балтач – Әтнә» – Борбаш автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң шушы автомобиль юлы буйлап 450 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м төньяк-көнчыгышка таба 39 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
6 нчы кушымта

**Балтач муниципаль районының «Югары Субаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Югары Субаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Югары Субаш авыл җирлеге Сасна, Урта Көшкәт, Чепья авыл җирлекләре, Арча муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы белән чиктәш.

Югары Субаш авыл җирлеге чиге Чепья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Югары Субаш, Чепья авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м һәм, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 950 м, көньяк-көнчыгышка таба 400 м уза, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, урман полосасы буйлап 1,1 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, кибеп баручы инешнең текә уңъяк ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м кибеп баручы инешкә кадәр, Югары Субаш, Чепья һәм Урта Көшкәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Субаш авылыннан 1,5 км көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Субаш авыл җирлеге чиге Урта Көшкәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 200 м уза, алга таба, Урта Көшкәт — Югары Субаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,5 км көньякка таба, яңадан шушы автомобиль юлына бүлеп

бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 550 м бара, Урта Көшкәт – Югары Субаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км, шушы автомобиль юлы буенча 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км, яңадан Урта Көшкәт – Югары Субаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньякка таба 700 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 550 м шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 36 нчы урман кварталы буйлап көньяк-көнчыгышка таба 500 м һәм көньякка таба 100 м бара, аннары, Көшкәт елгасын һәм аның текә уңъяк ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көнбатышка таба 850 м, көньяк-көнбатышка таба 900 м, көньякка таба 750 м уза, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м Югары Субаш, Урта Көшкәт һәм Сасна авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көшкәтбаш авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Югары Субаш авыл җирлеге чиге Сасна авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 250 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км, инешләрне һәм текә ярларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,9 км «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 51 нче урман кварталының көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 51 нче, 50 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,0 км 50 нче, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Югары Субаш, Сасна авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сасна Пүчинкәсе авылыннан 5,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Субаш авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып

Балтач муниципаль районы чиге буйлап Югары Субаш авыл җирлеге, Арча муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Сасна Пүчинкәсе авылыннан 5,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 17 нче (13 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Субаш авыл җирлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә 17 нче (13 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
7 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының «Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Карадуган авыл җирлеге Кече Лызи, Шубан авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы белән чиктәш.

Карадуган авыл җирлеге чиге Шубан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Карадуган, Шубан авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Таузар авылыннан 1,3 км төньяк-көнбатышта Шушма елгасында урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып Шушма елгасы агымы буенча аска таба 4,9 км уза, шуннан соң көнчыгышка таба 10 м шушы елга буйлап аның уңъяк ярына кадәр бара, сынык сызык ясап, Карадуган – Югары Шубан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Шушма елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, көньяк-көнчыгышка таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км уза, аннары «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

200 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 550 м 68 нче, 69 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, аннары урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м һәм көнчыгышка таба 250 м уза, аннары 69 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м Карадуган, Шубан һәм Кече Лызи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Лызи авылыннан 900 м төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Карадуган авыл җирлеге чиге Кече Лызи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып урман массивы буйлап көньяк-көнбатышка таба 50 м, Балтач – Кенәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Шушма елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км, чокыр төбе буенча 1,4 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, урман утыртмалары буйлап 350 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 900 м бара, шуннан соң урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 1,2 км, урман полосасы буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасы буйлап 200 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км уза, аннары көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап 1,1 км, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м Карадуган, Кече Лызи авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Ушма авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Карадуган авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып Балтач муниципаль районы чиге буйлап 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының «Куныр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Куныр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Куныр авыл җирлеге Нөнәгәр, Пыжмара, Чепья авыл җирлекләре, Марий Эл Республикасы һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Куныр авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Куныр авыл җирлеге, Марий Эл Республикасы һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Шода авылыннан 6,2 км көньяк-көнбатышта «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 1(Б) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Куныр, Пыжмара авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Иске Пукшинер авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Куныр авыл җирлеге чиге Пыжмара авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 300 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м уза, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 101 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м Кугуборка елгасындагы буа плотинасына кадәр бара, плотина буйлап көньякка таба 15 м һәм көнчыгышка таба 5 м, шуннан соң шушы

елга агымы буенча аска таба 9,5 км буага кадәр бара, аннары, Балтач – Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, буа буйлап 950 м көнчыгышка таба бара, Кугуборка елгасының кибеп баручы ермагы агымы буенча аска таба 500 м Кугуборка елгасының төп үзәненә кадәр уза, аннары шушы елга агымы буенча аска таба 4,2 км Куныр, Пыжмара һәм Нөнәгәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комаров-Завод авылыннан 450 м төньяк-көнбатышта Кугуборка елгасында урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Куныр авыл җирлеге чиге Нөнәгәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 4 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 850 м, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 650 м, шуннан соң урман полосасы буйлап көньяк-көнбатышка таба 400 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, Шода – Нослы автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м Куныр, Нөнәгәр һәм Чепья авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комаров-Завод авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Куныр авыл җирлеге чиге Чепья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, Шода – Нослы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 900 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм төньяк-көнбатышка таба 350 м, сәнәгать объекты буенча 100 м, Балтач – Әтнә автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, урман полосасы буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буенча 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м 16 нчы урман кварталының төньяк чигенә кадәр уза, шуннан соң көнбатышка таба 100 м шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап, аннары көньякка таба 400 м 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 550 м 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап

кибеп баручы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча аска таба 1,8 км аның Арборка елгасына койган җиренә кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 5,2 км уза, аннары, сынык сызык ясап, төньякка таба 3,7 км чокыр төбе буйлап аның очына кадәр бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, аннары урман полосасының төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 500 м, урман полосасы буйлап 200 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 800 м Куныр, Чепья авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Арбор авылыннан 3,3 км төньякта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Куныр авыл җирлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 1(Б) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

## Балтач муниципаль районының «Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кече Лызи авыл җирлеге «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Карадуган, Норма, Шубан авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы белән чиктәш.

Кече Лызи авыл җирлеге чиге Шубан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Лызи, Шубан һәм Карадуган авыл

җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Лызи авылыннан 900 м төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 69, 63, 64, 65 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шушма елгасына кадәр бара, алга таба шушы елга агымы буенча аска таба 3,5 км Кече Лызи, Шубан авыл җирлекләре һәм «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан Зур Лызи-2 авылыннан 750 м көнчыгышта Шушма елгасында урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Лызи авыл җирлеге чиге «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Кече Лызи авыл җирлеге, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Норма авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, 81 нче, 80 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км, аннары, сынык сызык ясап, 76, 74, 72 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,4 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,0 км, шуннан соң, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 1,6 км, 350 м көньяк-көнбатышка таба, 750 м төньяк-көнбатышка таба уза, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, аннары урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 1,0 км, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 500 м уза, шуннан соң 60 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 450 м, Балтач – Кенәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м бара, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м төньяк-көнбатышка таба, 850 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнчыгышка таба «Балтач – Кенәбаш» – Зур Лызи автомобиль юлына кадәр бара, шушы автомобиль юлы буйлап төньякка таба 250 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньякка таба, 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньякка таба, 300 м көнчыгышка таба, Шушма елгасының текә ярын кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба Шушма елгасына кадәр, 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кече Лызи авыл җирлеге чиге Норма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнчыгышка таба 700 м урман полосасына кадәр уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 350 м урман полосасына кадәр уза, аннары урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, аннары «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 17-К урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м 31-К урман кварталына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 4,3 км 31-К, 43-К, 54-К, 63-К, 69-К урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап Кече Лызи, Норма авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 5,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Лызи авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып Балтач муниципаль районы чиге буйлап Кече Лызи, Карадуган авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Ушма авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Лызи авыл җирлеге чиге Карадуган авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып урман массивы буйлап көньяк-көнбатышка таба 50 м, Балтач – Кенәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Шушма елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км, чокыр төбе буенча 1,4 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, урман утыртмалары буйлап 350 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны

кисеп үтеп, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 900 м бара, шуннан соң урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 1,2 км, урман полосасы буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасы буйлап 200 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км уза, аннары көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап 1,1 км, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>10 нчы кушымта

**Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт

Норма авыл җирлеге «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Борбаш, Кече Лызи, Салавыч, Сасна авыл җирлекләре, Арча, Кукмара һәм Саба муниципаль районнары белән чиктәш.

Норма авыл җирлеге чиге Салавыч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Норма, Салавыч һәм Сасна авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Сасна авылыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 700 м аның башка кибеп баручы инешкә койган җиренә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 1,3 км, көньяк-көнчыгышка таба 350 м уза, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 700 м, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м Шушма елгасының сулъяк ярына кадәр бара, Шушма елгасы буйлап 15 м һәм аның агымы

буенча аска таба 1,7 км уза, аннары Шушма елгасы буйлап 20 м көньяк-көнчыгышка таба аның уңъяк ярына кадәр бара, Казан — Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,9 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км, урман полосасы буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м Балтач — Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның шушы чиге буенча 250 м уза, шуннан соң, Балтач — Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, көньяк-көнчыгышка таба 50 м «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 71-К урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,6 км уза, аннары 900 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Норма, Салавыч һәм Борбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Борбаш авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Норма авыл җирлеге чиге Борбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Норма, Борбаш авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Нормабаш авылыннан 500 м көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 80-К, 77-К, 74-К урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 4,1 км уза, аннары 74-К, 75-К, 76-К урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 2,5 км бара, шуннан соң 950 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м Балтач — Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Норма авыл җирлеге чиге Кукмара муниципаль районы белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып Балтач муниципаль районы чиге буйлап Норма авыл җирлеге, Кукмара һәм Саба муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Нормабаш авылыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 33 нче урман

кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 38 нче (51 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Норма авыл җирлеге чиге Саба муниципаль районы белән чиктәш җирдә 38 нче (51 нче) тоташу ноктасыннан алып Балтач муниципаль районы чиге буйлап Норма авыл җирлеге, Саба һәм Арча муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 6,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче (50 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Норма авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 37 нче (50 нче) тоташу ноктасыннан алып Балтач муниципаль районы чиге буйлап Норма, Кече Лызи авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 5,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Норма авыл җирлеге чиге Кече Лызи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Норма, Кече Лызи авыл җирлекләре һәм «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнчыгышка таба 700 м урман полосасына кадәр уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 350 м урман полосасына кадәр уза, аннары урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, аннары «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 17-К урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м 31-К урман кварталына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 4,3 км 31-К, 43-К, 54-К, 63-К, 69-К урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Норма авыл җирлеге чиге «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Норма авыл җирлеге, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Сасна авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Түбән Сасна авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта Шушма елгасында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк-көнбатышка таба, Балтач — Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м көньякка таба, аннары көнчыгышка таба 500 м

автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырга кадәр уза, 550 м чокырның төньяк-көнбатыш чиге буйлап Казан – Малмыж автомобиль юлына кадәр бара, 150 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, Казан – Малмыж, «Казан – Малмыж» – Нормабаш автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Норма елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 900 м уза, шуннан соң, «Казан – Малмыж» – Нормабаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,3 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Норма авыл җирлеге чиге Сасна авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Шушма елгасы агымы буенча аска таба 500 м уза, шуннан соң Шушма елгасы буйлап көнчыгышка таба 10 м аның сулъяк ярына кадәр бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 800 м, урман утыртмалары буйлап 200 м, урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 350 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 40 м кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр бара, шушы инеш агымы буенча аска таба 450 м 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Нөнәгәр авыл җирлеге Куныр, Пыжмара, Смәил, Чепья авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Нөнәгәр авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Нөнәгәр, Пыжмара авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Комаров-Завод авылыннан 1,5 км төньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Нөнәгәр, Смәил авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Чутай авылыннан 1,9 км көньяк-көнбатышта Шушма елгасында урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нөнәгәр авыл җирлеге чиге Смәил авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып Арборка елгасы ермагының агымы буенча өскә таба 700 м Арборка елгасының төп үзәненә кадәр уза, алга таба шушы елга агымы буенча өскә таба 9,3 км Нөнәгәр, Смәил һәм Чепья авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тархан поселогыннан 300 м көньякта Арборка елгасында урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нөнәгәр авыл җирлеге чиге Чепья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып Арборка елгасы агымы буенча өскә таба 1,4 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, төньяк-көнбатышка таба 300 м һәм төньякка таба 50 м «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 21 нче урман кварталына кадәр бара, аннары шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, чокырны һәм зиратны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 150 м, көньяк-көнбатышка таба 550 м, чокырны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 650 м, сынык сызык ясап, 20 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 450 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, 20 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 200 м бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасы буйлап 450 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м Нөнәгәр, Чепья һәм Куныр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комаров-Завод авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нөнәгәр авыл җирлеге чиге Куныр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нөнәгәр, Куныр һәм Пыжмара авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комаров-Завод авылыннан 450 м төньяк-көнбатышта Кугуборка елгасында урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 850 м, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 650 м, шуннан соң урман полосасы буйлап көньяк-көнбатышка таба 400 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, Шода – Нослы автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нөнәгәр авыл җирлеге чиге Пыжмара авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 4 нче тоташу ноктасыннан алып Кугуборка елгасы агымы буенча аска таба 750 м аңа коя торган инешкә кадәр уза, шуннан соң 1,6 км инеш агымы буенча өскә таба 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нөнәгәр авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге Пыжмара авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Нөнәгәр авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Нөнәгәр, Пыжмара авыл җирлекләренең басу аша кишәрлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Чутай авылыннан 26,5 км көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Нөнәгәр, Пыжмара авыл җирлекләренең басу аша кишәрлекләре һәм Киров өлкәсе

чикләре тоташкан урында Чутай авылыннан 26,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нөнәгәр авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Пыжмара авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, агач-куак массивының төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 1,5 км уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км бара, аннары агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 30 м 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

## Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Пыжмара авыл җирлеге Куныр, Нөнәгәр авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Пыжмара авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Пыжмара, Куныр авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Иске Пукшинер авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Пыжмара, Нөнәгәр авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Комаров-Завод авылыннан 1,5 км төньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пыжмара авыл җирлеге чиге Нөнәгәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Пыжмара, Нөнәгәр һәм Куныр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комаров-Завод авылыннан 450 м төньяк-көнбатышта Кугуборка елгасында урнашкан 4 нче тота-

шу ноктасыннан алып Кугуборка елгасы агымы буенча аска таба 750 м аңа коя торган инешкә кадәр уза, шуннан соң 1,6 км инеш агымы буенча өскә таба 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Пыжмара авыл җирлеге чиге Куныр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 300 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м уза, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 101 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м Кугуборка елгасындагы буа плотинасына кадәр бара, плотина буйлап көньякка таба 15 м һәм көнчыгышка таба 5 м, шуннан соң шушы елга агымы буенча аска таба 9,5 км буага кадәр бара, аннары, Балтач – Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, буа буйлап 950 м көнчыгышка таба бара, Кугуборка елгасының кибеп баручы ермагы агымы буенча аска таба 500 м Кугуборка елгасының төп үзәненә кадәр уза, аннары шушы елга агымы буенча аска таба 4,2 км 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Пыжмара авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге Нөнәгәр авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Пыжмара авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Пыжмара, Нөнәгәр авыл җирлекләренең басу аша кишәрлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Чутай авылыннан 26,5 км көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Пыжмара, Нөнәгәр авыл җирлекләренең басу аша кишәрлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Чутай авылыннан 26,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Пыжмара авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Нөнәгәр авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, агач-куак массивының төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 1,5 км уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км бара, аннары агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 30 м 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының «Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Салавыч авыл җирлеге Борбаш, Норма, Сасна һәм Яңгул авыл җирлекләре белән чиктәш.

Салавыч авыл җирлеге чиге Сасна авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Салавыч, Сасна һәм Норма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Сасна авылыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып, кибеп баручы инешнең текә сулъяк ярын кисеп үтеп, төньякка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Салавыч, Сасна һәм Яңгул авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Сасна авылыннан 2,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Салавыч авыл җирлеге чиге Яңгул авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 900 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км, урман полосасы буйлап 550 м уза, шуннан соң көнчыгышка таба 200 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, урман полосасы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасы буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км һәм, канауны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 50 м, канауны кисеп үтеп, агач-куак массивы буенча 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м Шушма елгасының сулъяк ярына кадәр бара, шуннан соң шушы елга буйлап 20 м һәм аның агымы буен-

ча аска таба 350 м бара, аннары Шушма елгасы буенча көньяк-көнчыгышка таба 35 м аның уңъяк ярына кадәр, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,1 км, «Балтач – Әтнә» – Борбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м Салавыч, Яңгул һәм Борбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Салавыч Сәрдегәне авылыннан 1,5 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Салавыч авыл җирлеге чиге Борбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Салавыч, Борбаш һәм Норма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Борбаш авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып, Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,6 км «Балтач – Әтнә» – Борбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км, 250 м яңадан шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, «Балтач – Әтнә» – Борбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Салавыч авыл җирлеге чиге Норма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 700 м аның башка кибеп баручы инешкә койган җиренә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 1,3 км, көньяк-көнчыгышка таба 350 м уза, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 700 м, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м Шушма елгасының сулъяк ярына кадәр бара, Шушма елгасы буйлап 15 м һәм аның агымы буенча аска таба 1,7 км уза, аннары Шушма елгасы буйлап 20 м көньяк-көнчыгышка таба аның уңъяк ярына кадәр бара, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профиль-

ле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,9 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км, урман полосасы буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның шушы чиге буенча 250 м уза, шуннан соң, Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, көньяк-көнчыгышка таба 50 м «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 71-К урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,6 км уза, аннары 900 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының «Смәил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Смәил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Смәил авыл җирлеге Борнак, Нөнәгәр, Чепья, Шеңшеңәр авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

Смәил авыл җирлеге чиге Чепья авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Смәил, Чепья һәм Борнак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карык-Серма авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 500 м урман полосасы буйлап уза, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап

150 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км, Арбор – Шеңшеңәр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнчыгышка таба 900 м, төньяк-көнчыгышка таба 250 м Смәил, Чепья һәм Нөнәгәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тархан поселогыннан 300 м көньякта Арборка елгасында урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Смәил авыл җирлеге чиге Нөнәгәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Смәил, Нөнәгәр авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Чутай авылыннан 1,9 км көньяк-көнбатышта Шушма елгасында урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып Арборка елгасы ермагының агымы буенча өскә таба 700 м Арборка елгасының төп үзәненә кадәр уза, алга таба шушы елга агымы буенча өскә таба 9,3 км 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Смәил авыл җирлеге чиге Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Смәил, Шеңшеңәр авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе чикләре тоташкан урында Шеңшеңәр авылыннан 600 м төньякта Шушма елгасында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Смәил авыл җирлеге чиге Шеңшеңәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Шушма елгасы агымы буенча өскә таба 2,7 км уза, алга таба шушы елга буйлап көньяк-көнбатышка таба 10 м аның уңъяк ярына кадәр бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км Шушма елгасының уңъяк ярына кадәр уза, аннары шушы елга буйлап 10 м һәм, Арбор – Шеңшеңәр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның агымы буенча өскә таба 3,4 км Смәил, Шеңшеңәр һәм Борнак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Смәил авылыннан 900 м көньяк-көнбатышта Шушма елгасында урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Смәил авыл җирлеге чиге Борнак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып 850 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасың көньяк-көнбатыш чиге буйлап, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 300 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң көньякка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 750 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап

650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км кибеп баручы инешкә кадәр бара, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба 2,0 км бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шушма елгасына кадәр уза, Шушма елгасы буенча 10 м 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Балтач муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

## Балтач муниципаль районының «Сасна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Сасна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Сасна авыл җирлеге «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Югары Субаш, Норма, Салавыч, Урта Көшкәт, Шубан, Яңгул авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы белән чиктәш.

Сасна авыл җирлеге чиге Югары Субаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сасна, Югары Субаш һәм Урта Көшкәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көшкәтбаш авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 250 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км, инешләрне һәм текә ярларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, ур-

ман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,9 км «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 51 нче урман кварталының көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 51 нче, 50 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,0 км 50 нче, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Сасна, Югары Субаш авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сасна Пүчинкәсе авылыннан 5,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бехтерев авыл җирлеге чиге Илмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, сынык сызык ясап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасы буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
6 нчы кушымта

**Алабуга муниципаль районының
«Олы Елово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Олы Елово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олы Елово авыл җирлеге Морт, Мурзиха, Татар Дөм-Дөме, Яковлево авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш.

Олы Елово авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Олы Елово, Яковлево авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Анзирка авылыннан 250 м төньяк-көнбатышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Алабуга муниципаль районы чиге буйлап Олы Елово, Татар Дөм-Дөме авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Айталан авылыннан 4,6 км көнбатышта Нократ елгасы акваториясендә урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Елово авыл җирлеге чиге Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Нократ елгасы акваториясе буенча 500 м көнчыгышка таба, утрауны кисеп үтеп, аның сул ярына кадәр, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, күлне кисеп үтеп, 200 м, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, алга таба көньяк-көнчыгышка агач-куак массивы буйлап 100 м Шүрнәк Заумар күленә кадәр бара, әлеге күл буенча 750 м уза, аннары 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 50 м бара, алга таба 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, Грязный күленә

кадәр уза, аннары әлеге күл буенча 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көнчыгышка таба аның көнчыгыш ярына кадәр бара, алга таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Югары күленә кадәр уза, әлеге күлнең көньяк-көнчыгыш яры буйлап 800 м бара, аннары 1,2 км төньякка таба 16 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м төньяк-көнчыгышка таба, чокырларны кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнбатышка таба, 40 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 1,2 км көнчыгышка таба 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, алга таба көньяк-көнчыгышка чокыр төбе буенча 1,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Олы Шүрнәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,0 км бара, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба 89 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 150 м көньяк-көнчыгышка таба 89 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба көнчыгышка таба 300 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Елово, Татар Дөм-Дөме һәм Морт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Айталан авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Елово авыл җирлеге чиге Морт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 35 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк чиге буйлап 950 м төньякка таба, 450 м төньяк-көнчыгышка таба, Вонюшка елгасын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 39 нчы, 42 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,3 км көньяк-көнбатышка таба Олы Елово, Морт һәм Мурзиха авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Токмаш авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Елово авыл җирлеге чиге Мурзиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 48 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 48 нче урман кварталының

төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Вонюшка елгасын кисеп үтеп, 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км уза, аннары 100 м көньякка таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 49 нчы, 50 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 3,0 км, чокырны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Елово, Мурзиха һәм Яковлево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яковлево авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Елово авыл җирлеге чиге Яковлево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньяк-көнбатышка таба, чокырларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м чокырның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 100 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м урман полосасы буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Олы Шүрнәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, чокырларны, агач-куак массивларын кисеп үтеп, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 250 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 3,0 км көнбатышка таба, текә ярны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
7 нче кушымта

## Алабуга муниципаль районының «Олы Качык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Олы Качык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре

чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олы Качык авыл җирлеге «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге, Илмәт, Бехтерев, Лекарево һәм Танай авыл җирлекләре белән чиктәш.

Олы Качык авыл җирлеге чиге Илмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Качык, Илмәт һәм Бехтерев авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көек авылыннан 6,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 800 м урман полосасы буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м урман полосасы буйлап, чокырны кисеп үтеп, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 2,5 км урман полосасы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км көньяк-көнбатышка таба, 1,5 км көньяк-көнчыгышка таба, 700 м төньяк-көнчыгышка таба Олы Качык, Илмәт һәм Лекарево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көек авылыннан 2,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Качык авыл җирлеге чиге Бехтерев авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Качык, Бехтерев авыл җирлекләре һәм «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Гәр авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны һәм яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, Каринка елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 2,4 км өскә таба аның чишмә башына кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба, агач-куак массивын кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м чокырның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м төньяк-көнбатышка таба, 750 м көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м төньяк-көнбатышка таба бара, агач-куак полосасын кисеп үтеп, 150 м чокыр төбе буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м чокыр төбе бөенча уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м төньякка таба инешкә кадәр бара, аның агымы буенча 2,4 км өскә таба аның чишмә башына кадәр уза, аннары 250 м төньякка таба, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба көнбатышка 1,0 км урман полосасының төньяк чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Качык авыл җирлеге чиге «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Олы Качык авыл җирлеге, «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Танай

авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Хлыстово авылыннан 350 м көньякта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып 2,9 км көнчыгышка таба Алабуга шәһәренә керү автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, аның агымы буенча 2,3 км өскә таба буага кадәр уза, 100 м төньяк-көнчыгышка таба буа буйлап бара, кибеп баручы инеш агымы буенча 1,3 км өскә таба уза, аннары 40 м көнбатышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 110 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 50 м бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м, урман полосасын, чокырларны, агач-куак массивын, инешне һәм профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,5 км һәм төньякка таба 400 м уза, алга таба «Алабуга» махсус икътисадый зонасының көнбатыш чиге буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м төньякка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 1,1 км көнбатышка таба, профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны, чокырны, инешне һәм яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 1,7 км төньякка таба, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба, чокырларны, кибеп баручы инешне, яр буе агач-куак полосасын, текә ярны һәм урман массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,3 км төньяк-көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 1,1 км көнбатышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 750 м көнчыгышка таба «Алабуга» махсус икътисадый зонасының төньяк чиге буйлап 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Качык авыл җирлеге чиге Танай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып Танай елгасы агымы буенча 1,3 км өскә таба уза, аннары инеш агымы буенча 650 м өскә таба бара, алга таба төньяк-көнбатышка «Мәскәү – Уфа» – Олы Тарлау автомобиль юлы буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

150 м уза, аннары 2,6 км көньяк-көнбатышка таба Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Танай елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 5,7 км өскә таба уза, алга таба көньякка 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 950 м һәм көньяк чиге буйлап 3,2 км көньяк-көнбатышка таба Олы Качык, Танай һәм Лекарево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Малоречинский поселогыннан 700 м көньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Качык авыл җирлеге чиге Лекарево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, «Мәскәү — Уфа» — Малоречинский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, аннары 750 м төньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 56 нчы, 55 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 1,1 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 54 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м бара, алга таба төньяк-көнчыгышка 54 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 53 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 400 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 53 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м уза, алга таба төньяк-көнчыгышка 53 нче, 52 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 450 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 52 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, аннары төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 52 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 100 м бара, алга таба төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, аннары 52 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба 11 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының «Олы Шүрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Олы Шүрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олы Шүрнәк авыл җирлеге Морт, Иске Күклек, Татар Дөм-Дөме авыл җирлекләре, Мамадыш муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Олы Шүрнәк авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Олы Шүрнәк, Татар Дөм-Дөме авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Татар Дөм-Дөме авылыннан 4,7 км көньяк-көнбатышта Нократ елгасы акваториясендә урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып Алабуга муниципаль районы чиге буйлап Олы Шүрнәк авыл җирлеге, Мамадыш муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Красная Горка поселогыннан 2,9 км төньяк-көнбатышта Нократ елгасы акваториясендә урнашкан 4 нче (16 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шүрнәк авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 4 нче (16 нчы) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Олы Шүрнәк, Иске Күклек авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Үмәк авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шүрнәк авыл җирлеге чиге Иске Күклек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 1 нче тоташу ноктасыннан алып 700 м көньяк-көнчыгышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының төньяк-көн-

чыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, 9 нчы урман кварталы буйлап 1,3 км уза, текә ярлары һәм яр буе агач-куак массивлары белән бергә Үмәк елгасын берничә тапкыр кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба урман массивы буйлап 150 м, 81 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м уза, алга таба 250 м көньяк-көнчыгышка таба 10 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Морт – Үмәк – Бажениха автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба көньяк-көнчыгышка 1,5 км урман полосасы буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Олы Шүрнәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм аның юл буе урман полосаларын, чокырны, текә ярлары һәм чокыр буе урман полосалары белән кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м урман полосасы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Морт – Үмәк – Бажениха автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм аның юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба бара, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, текә ярларны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман утыртмалары буйлап, Күклек елгасын һәм текә ярларны кисеп үтеп, 2,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Олы Шүрнәк, Иске Күклек һәм Морт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Шүрнәк авылыннан 3,6 км көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шүрнәк авыл җирлеге чиге Морт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м көньякка таба, «Мәскәү – Уфа» – Морт – Үмәк – Бажениха автомобиль

юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 550 м көньяк-көнбатышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 25 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 24 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 1,9 км көньяк-көнбатышка таба 23 нче, 27 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Олы Шүрнәк, Морт һәм Татар Дөм-Дөме авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Шүрнәк авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шүрнәк авыл җирлеге чиге Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м төньяк-көнбатышка таба һәм 550 м төньякка таба уза, 100 м зиратның көнбатыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба 250 м урман полосасы буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Олы Шүрнәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, 950 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,2 км көньякка таба бара, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 84 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 550 м, чокырларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 84 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, чокырларны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 84 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, агач-

куак массивы буйлап 50 м, агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, чокырны, агач-куак массивын һәм текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, 78 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 400 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба, агач-куак массивларын кисеп үтеп, сазлык буенча 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 78 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, сазлык буенча 550 м, агач-куак массивы буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, 78 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, аннары төньякка таба әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 200 м, күл буенча 50 м, аны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба көнбатышка, күлне кисеп үтеп, 100 м сазлык буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 14 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 400 м уза, 50 м комлык буенча, 200 м Нократ акваториясе буйлап 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

## Алабуга муниципаль районының «Костенеево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Костенеево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Костенеево авыл җирлеге Мурзиха, Танай, Яковлево авыл җирлекләре, Мамадыш һәм Түбән Кама муниципаль районнары белән чиктәш.

Костенеево авыл җирлеге чиге Яковлево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Костенеево, Яковлево авыл җирлекләре һәм Мамадыш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Черенга авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча 1,3 км аска таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 2,2 км төньяк-көнчыгышка таба, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 1,2 км көнчыгышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көнчыгышка таба, 850 м төньякка таба бара, агач-куак массивы буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 150 м, чокырны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны һәм башка кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 700 м өскә таба аның чишмә башына кадәр уза, аннары, сынык сызык ясап, 3,8 км төньяк-көнчыгышка таба, текә ярларны, чокырны, инешне, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 200 м торф чыгару урыннары буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап Костенеево, Яковлево һәм Мурзиха авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Костенеево авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта Анзирка елгасында урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Костенеево авыл җирлеге чиге Мурзиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып Анзирка елгасы агымы буенча 5,4 км өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,7 км өскә таба уза, алга таба 6,5 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Костенеево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Армалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Костенеево авыл җирлеге чиге Түбән Кама муниципаль районы белән чиктәш җирдә Костенеево, Танай авыл җирлекләре һәм Түбән Кама муниципаль районы чикләре тоташкан урында Покровский авылыннан 4,4 км көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан

алып Алабуга муниципаль районы чиге буйлап Костенеево авыл җирлеге, Мамадыш һәм Түбән Кама муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Свиногорье авылыннан 2,4 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 453535,01, Y = 2271504,14 координаталы 38 нче (61 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Костенеево авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 38 нче (61 нче) тоташу ноктасыннан алып Алабуга муниципаль районы чиге буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Костенеево авыл җирлеге чиге Танай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасы буйлап, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м, әлеге урман кварталы буйлап 500 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның агымы буенча 450 м башка инешкә койган җиренә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 950 м аска таба Криуша елгасы кушылдыгына кадәр уза, алга таба Криуша елгасы кушылдыгы агымы буенча 500 м аска таба бара, әлеге кушылдыкның уң яры буенча 300 м көнбатышка таба уза, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 600 м көньякка таба һәм 2,8 км көньяк-көнчыгышка таба 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

**Алабуга муниципаль районының «Лекарево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Лекарево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре

чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Лекарево авыл җирлеге Илмәт, Олы Качык, Морт, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре белән чиктәш.

Лекарево авыл җирлеге чиге Илмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Лекарево, Илмәт һәм Олы Качык авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көек авылыннан 2,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 52 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 650 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Лекарево, Илмәт һәм Морт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ядегәр авылыннан 3,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Лекарево авыл җирлеге чиге Олы Качык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Лекарево, Олы Качык һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Малоречинский поселогыннан 700 м көньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, «Мәскәү — Уфа» — Малоречинский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, аннары 750 м төньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 56 нчы, 55 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 1,1 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 54 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м бара, алга таба төньяк-көнчыгышка 54 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 53 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 400 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 53 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м уза, алга таба төньяк-көнчыгышка 53 нче, 52 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 450 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 52 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, аннары төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 52 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 100 м бара,

алга таба төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, аннары 52 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба 11 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Лекарево авыл җирлеге чиге Танай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман массивы буйлап, 300 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Малоречинский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньякка таба 850 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м бакчачылык ширкәтенең көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 2,2 км аска таба башка кибеп баручы инешкә кушылган җиренә кадәр бара, аның агымы буенча 2,1 км өскә таба чишмә башына кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба 150 м агач-куак массивы буйлап, Алабуга – Лекарево – Олы Армалы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,6 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 550 м өскә таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 350 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 4,9 км көньяк-көнбатышка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Лекарево, Танай, Костенеево һәм Мурзиха авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Армалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Лекарево авыл җирлеге чиге Мурзиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куак полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м көнбатышка таба, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,9 км аска таба Анзирка елгасына койган җиргә кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 1,8 км өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр бара, аның агымы буенча, Яңа Мурзиха авылын «Мәскәү – Уфа» – Морт – Үмәк – Бажениха автомобиль юлы белән тоташтыра торган профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км өскә таба уза, төньяк-көнбатышка таба, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 40 м урман массивы буйлап Лекарево, Мурзиха һәм Морт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Токмаш авылыннан 3,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Лекарево авыл җирлеге чиге Морт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк чиге буйлап 1,2 км көнчыгышка таба уза, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, аның агымы буенча 1,1 км аска таба буага кадәр уза, буаның уң яры буйлап 1,6 км көнчыгышка таба дамбага кадәр бара, аннары дамба буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба Мәмәт инешенә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 450 м аска таба аның Шаршала инешенә койган җиренә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 5,2 км өскә таба уза, алга таба төньякка, текә ярны кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 700 м төньякка таба, берничә тапкыр чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнчыгышка таба уза, урман утыртмалары буенча 150 м, чокырны, кибеп баручы инешне һәм аның яр буе агач-куак массивлары булган текә ярын һәм башка текә ярны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының «Морт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Морт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Морт авыл җирлеге Илмәт, Олы Елово, Олы Шүрнәк, Лекарево, Мурзиха, Иске Күклек, Иске Юраш һәм Татар Дөм-Дөме авыл җирлекләре белән чиктәш.

Морт авыл җирлеге чиге Мурзиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Морт, Мурзиха һәм Лекарево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Токмаш авылыннан 3,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 650 м төньяк-көнбатышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 47 нче, 46 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, алга таба 1,6 км көньяк-көнбатышка таба 46 нчы, 45 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 2,4 км төньяк-көнбатышка таба 45 нче, 42 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Морт, Мурзиха һәм Олы Елово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Токмаш авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Морт авыл җирлеге чиге Олы Елово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Морт, Олы Елово һәм Татар Дөм-Дөме авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Айталан авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 35 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк чиге буйлап 950 м төньякка

таба, 450 м төньяк-көнчыгышка таба, Вонюшка елгасын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 39 нчы, 42 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,3 км көньяк-көнбатышка таба 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Морт авыл җирлеге чиге Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 3,1 км төньяк-көнчыгышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 35, 31, 27 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап Морт, Татар Дөм-Дөме һәм Олы Шүрнәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Шүрнәк авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Морт авыл җирлеге чиге Олы Шүрнәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Морт, Олы Шүрнәк һәм Иске Күклек авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Шүрнәк авылыннан 3,6 км көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м көньякка таба, «Мәскәү – Уфа» – Морт – Үмәк – Бажениха автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 550 м көньяк-көнбатышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 25 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 24 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 1,9 км көньяк-көнбатышка таба 23 нче, 27 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Морт авыл җирлеге чиге Иске Күклек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 25 нче, 22 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 1,6 км уза, аннары 21 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба Морт, Иске Күклек һәм Иске Юраш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чиркәс авылыннан 1,6 км көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Морт авыл җирлеге чиге Иске Юраш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-

көнчыгышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 21 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 21 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 21 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары көньякка таба 21 нче, 22 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 2,4 км бара, алга таба 700 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Морт, Иске Юраш һәм Илмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Черкасово авылыннан 4,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Морт авыл җирлеге чиге Илмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Морт, Илмәт һәм Лекарево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ядегәр авылыннан 3,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны һәм Морт – Сосновый Юраш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 6,1 км көнбатышка таба уза, аннары 450 м төньяк-көнчыгышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 26 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 26 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 400 м көньяк-көнбатышка таба 26 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары 500 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Морт авыл җирлеге чиге Лекарево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк чиге буйлап 1,2 км көнчыгышка таба уза, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, аның агымы буенча 1,1 км аска таба буага кадәр уза, буаның уң яры буйлап 1,6 км көнчыгышка таба дамбага кадәр бара, аннары дамба буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба Мәмәт инешенә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 450 м аска таба аның Шаршала

инешенә койган җиренә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 5,2 км өскә таба уза, алга таба төньякка, текә ярны кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 700 м төньякка таба, берничә тапкыр чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнчыгышка таба уза, урман утыртмалары буенча 150 м, чокырны, кибеп баручы инешне һәм аның яр буе агач-куак массивлары булган текә ярын һәм башка текә ярны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алабуга муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының «Мурзиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Мурзиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Мурзиха авыл җирлеге Олы Елово, Костенеево, Лекарево, Морт һәм Яковлево авыл җирлекләре белән чиктәш.

Мурзиха авыл җирлеге чиге Костенеево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мурзиха, Костенеево һәм Яковлево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Костенеево авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта Анзирка елгасында урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып Анзирка елгасы агымы буенча 5,4 км өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,7 км өскә таба уза, алга таба 6,5 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Мур-

зиха, Костенеево һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Армалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Мурзиха авыл җирлеге чиге Яковлево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 50 м агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 61 нче, 62 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,4 км бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 62 нче, 60 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 60 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, Яңа Мурзиха һәм Яковлево авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба уза, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Яңа Мурзиха авылын Токмаш авылы белән тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кабат кисеп үтеп, 1,3 км төньяк-көнбатышка таба уза, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, 50 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Вонюшка елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 2,0 км аска таба уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 150 м төньяк-көнбатышка таба Мурзиха, Яковлево һәм Олы Елово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яковлево авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

